КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2020 ел, 8 декабрь | г.Казань | № 1107

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник тире-венерология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә профессор Ге Александр Генрихович исемен бирү турында

Казан Император Университетының медицина факультетында тире һәм венерия авырулары кафедрасына нигез салучы, профессор Ге Александр Генрихович исемен мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник тире-венерология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә профессор Ге Александр Генрихович исемен бирү турында тәкъдимен кабул итәргә һәм алга таба да аны «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Ге Александр Генрихович исеменендәге Республика клиник тире-венерология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе дип атарга.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына 30 көн эчендә «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник тире-венерология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе уставына тиешле үзгәрешләр кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин